МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17 март 2026ел № М 120

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында нигезләмәне раслау турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 8 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм федераль дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирү хакында» 2009 елның 18 маендагы 559 номерлы Указы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында нигезләмәне кушымтада каралганча расларга.

2. Шәһәр Хакименең түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) 2015 елның 18 февралендә «Челнинские известия» газетасының 11 нче санында бастырып чыгарылган «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы

гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы;

2) 2015 елның 18 мартында «Челнинские известия» газетасының 19 нчы санында бастырып чыгарылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 24 февралендәге М 58 номерлы;

3) «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 1 февралендәге М 34 номерлы;

4) 2018 елның 2 июлендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган, 2018 елның 4 июлендә «Челнинские известия» газетасының 43 нче санында бастырып чыгарылган «Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге

М 692 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 29 июнендәге М 293 номерлы;

5) 2021 елның 26 маенда Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 14 маендагы М 186 номерлы;

6) 2022 елның 18 мартында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 мартындагы М 94 номерлы;

7) «Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 17 июнендәге М 254 номерлы;

8) 2022 елның 9 ноябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар

бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 2 ноябрендәге М 484 номерлы;

9) 2023 елның 31 мартында Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2023 елның 24 мартындагы М 113 номерлы;

10) 2023 елның 11 октябрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү турындагы нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2023 елның 3 октябрендәге М 454 номерлы;

11) 2023 елның 27 декабрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары

турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәреш кертү турында» 2023 елның 20 декабрендәге М 604 номерлы;

12) 2024 елның 28 февралендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 20 февралендәге М 72 номерлы;

13) 2024 елның 17 июлендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 11 июлендәге М 355 номерлы;

14) 2024 елның 25 декабрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында https://pravo.tatarstan.ru урнаштырылган «Шәһәр Хакименең 2014 елның 21 ноябрендәге М 692 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәтнең гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында,

мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр вазыйфа биләгәндә керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иреңең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган вазыйфалар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 19 декабрендәге М 605 номерлы.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башлыгы урынбасарына, Контроль-хисап палатасы Рәисенә, Башкарма комитет Җитәкчесенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2026 елның 17 мартындагы
М 120 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү хакында нигезләмә

1. Әлеге нигезләмә белән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә, контракт буенча Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасыннан тыш, муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан үзләренең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук үзләренең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар (алга таба – керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар) бирү тәртибе билгеләнә.

2. Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар һәм Башкарма комитет Җитәкчесе вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирү тәртибе Татарстан Республикасының «Муниципаль вазыйфа яисә контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфалар яисә контракт буенча җирле хакимият башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында мәгълүматлар бирү тәртибе турында» 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Законы белән билгеләнгән.

3. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирү бурычы федераль законнар нигезендә йөкләнә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә гражданнар вазыйфага билгеләнгәндә үзләренең керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә бурычлы булган муниципаль хезмәт вазыйфалары исемлегендә (алга таба — вазыйфалар исемлеге) каралган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданга (алга таба – граждан);

2) вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәргә (алга таба - муниципаль хезмәткәр);

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы муниципаль хезмәткәргә (алга таба – исемлектә каралган вазыйфага кандидат).

4. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган белешмә формасы буенча тапшырыла:

1) гражданнар тарафыннан - аларны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләгәндә;

2) исемлектә каралган вазыйфаларга кандидатлар тарафыннан - Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләгәндә;

3) муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан – «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүматлар бирү өчен нигезләр барлыкка килгән очракта - мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң килә торган елның 30 апреленнән соңга калмыйча.

5. Граждан Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә вазыйфалар исемлегендә каралган муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгәндә:

1) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган үз керемнәре (элеккеге эш урыны яки сайлаган вазыйфасын биләү урыны буенча алынган керемнәрне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматларны, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына (хисап датасына) кадәр аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны;

2) муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен граждан тарафыннан документлар тапшыру елыннан алдагы календарь ел өчен үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматларны, шулай ук муниципаль хезмәт вазыйфасын биләү өчен граждан тарафыннан документлар тапшыру аеннан алдагы айның беренче числосына (хисап датасына) кадәр аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны.

6. Исемлектә каралган вазыйфага кандидат әлеге нигезләмәнең 5 пункты нигезендә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыра.

7. Муниципаль хезмәткәр тапшыра:

1) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүматлар бирү өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чорында) барлык чыганаклардан алынган үз керемнәре (акчалата түләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) турында мәгълүматларны, шулай ук хисап чоры ахырына торышы буенча аның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны;

2) «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында мәгълүматлар бирү өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чорында) үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) турында мәгълүматларны, шулай ук хисап чоры ахырына торышы буенча аларның милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматларны.

8. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар, әлеге нигезләмә нигезендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының кадрлар хезмәтенә (алга таба – кадрлар хезмәте) тапшырыла.

9. Граждан, исемлектә каралган вазыйфага кандидат, муниципаль хезмәткәр үзләре тарафыннан кадрлар хезмәтенә тапшырылган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларда нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмаган яки тулысынча чагылдырылмаган яисә хаталар булган очракта, алар, әлеге нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, төгәллек кертелгән мәгълүматларны тапшырырга хокуклы.

Граждан төгәллек кертелгән мәгълүматларны әлеге нигезләмәнең 4 пунктындагы 1 пунктчасы нигезендә мәгълүматлар тапшырылган көннән башлап бер ай эчендә тапшыра ала.

Исемлектә каралган вазыйфага кандидат төгәллек кертелгән мәгълүматларны әлеге игезләмәнең 4 пунктындагы 2 пунктчасы нигезендә мәгълүматлар тапшырылган көннән башлап бер ай эчендә тапшыра ала.

Муниципаль хезмәткәр төгәллек кертелгән мәгълүматларны әлеге нигезләмәнең 4 пунктының 3 пунктчасында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә тапшыра ала.

10. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар Россия Федерациясе Президенты тарафыннан расланган, Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында

урнаштырылган «БК белешмәләре» махсус программа тәэминатыннан файдаланып тутырылган белешмә формасы буенча тапшырыла, аңа сылтама шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында урнаштырыла.

11. Объектив сәбәпләр буенча, исемлектә каралган вазыйфага кандидат, муниципаль хезмәткәр тарафыннан үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирелмәгән очракта, әлеге факт Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиядә каралырга тиеш.

12. Әлеге нигезләмә нигезендә бирелгән керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

13. Әлеге нигезләмә нигезендә бирелә торган керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар федераль закон буенча дәүләт сере булып исәпләнә торган мәгълүматларга кертелмәгән очракта, алар конфиденциаль характердагы мәгълүматлар булып тора.

Әлеге мәгълүматлар Яр Чаллы шәһәре җирле үзидарә органы җитәкчесенә һәм җирле үзидарәнең муниципаль хезмәт вазыйфаларына билгеләү һәм алардан азат итү вәкаләтләре бирелгән башка вазыйфаи затларына, шулай ук, федераль законнарда каралган очракларда, башка вазыйфаи затларга тапшырыла.

14. Вазыйфаи бурычларына керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар белән эшләү керә торган һәм аларны таратуда яки Россия Федерациясе законнарында күздә тотылмаган максатларда файдалануда гаепләнүче муниципаль хезмәткәрләр Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

15. Әлеге нигезләмә нигезендә бирелгән керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар һәм әлеге мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү нәтиҗәләре турында мәгълүмат (Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча тиешле комиссия карары) муниципаль хезмәткәрнең шәхси делосына теркәлә.

Әлеге нигезләмә нигезендә кадрлар хезмәтенә керемнәре турында, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат биргән граждан, исемлектә каралган вазыйфага кандидат муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, аларның язмача гаризасы буенча мондый мәгълүматлар башка документлар белән бергә күрсәтелгән затларга кире кайтарыла.

16. Керемнәр турында, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар бирелмәгән, күрәләтә тулы булмаган мәгълүматлар бирелгән очракта, граждан, исемлектә каралган вазыйфага кандидат тиешле муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасыннан азат ителә яки Россия Федерациясе законнары нигезендә башка төр дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

И.А. Сәгыйдуллина